ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.08.2023 Олы Кайбыч ав. № 334

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 29 октябрендәге 471 карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы милкендәге, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге өченче затларның хокукларыннан азат булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 октябрендәге 471 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге өченче затларның хокукларыннан азат булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлегенә (алга таба - Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Муниципаль мөлкәт исемлегеннән түбәндәге эчтәлектәге п.1не төшереп калдырырга:

| т/б | Мөлкәт исеме | Бинаның гомуми мәйданы | Урнашу урыны (адресы) |
|---|---|---|---|
| 6 | Бина (16:21:090101:339 кадастр номерлы 1960 елда төзелгән торак булмаган 1 катлы бина, балалар бакчасы) | 84,4 | Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Ябалак авыл җирлеге, Ябалак ав., Якты ур., 1 нче й. |

1.2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 29 октябрендәге 471 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген түбәндәге эчтәлекле пунктлар белән тулыландырырга:

| т/б | Мөлкәт исеме | Бинаның гомуми мәйданы | Урнашу урыны (адресы) |
|---|---|---|---|
| 7 | 16:21:040101:790 кадастр номерлы торак булмаган балалар бакчасы бинасы (кулланылмый торган) | 299,9 | Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Ульянково авыл җирлеге, Ульянково ав., Мәктәп ур. |
| 8 | 16:21:010104:104 кадастр номерлы административ бинада бүлмәләр | 110,4 | Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авыл җирлеге, Олы Кайбыч ав., Р.Гарәфетдинов ур., 1В нче йорт |

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе О.Д. Макаровага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров